**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАР

2021 елның 24 ноябреннән № 15-112

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 29-163 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы регламентын Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатыннан, «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 29-163 номерлы карары белән расланган ( 29.12.2017 ел, № 32-187, 29.12.2020 ел, №4-30 үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Совет эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча район башлыгы:

1) районны башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә тәкъдим итә, ышанычнамәсез район исеменнән эш итә;

2) район Советы эшен оештыра, район Советы утырышларын җыя һәм аларда рәислек итә;

3) район Советы кабул иткән норматив хокукый актларга кул куя һәм халыкка җиткерә;

4) үз вәкаләтләре кысаларында район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара;

5) район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзи;

6) район Советы эшендә хәбәрдарлык һәм җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу буенча чаралар күрә;

7) гражданнарны кабул итүне, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;

8) район Советы сессияләре беркетмәләренә кул куя;

9) район Советы эшчәнлеген карап тоту һәм тәэмин итү өчен район бюджетында каралган чыгымнар буенча акча бүлүче булып тора;

10) район исеменнән дәүләт хакимияте органнары, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән икътисадый һәм социаль-мәдәни

өлкәләрдә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек һәм гамәлләрне координацияләү турында шартнамә һәм килешүләр төзи;

11) җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

12) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль район башлыклары карамагына кертелгән башка вәкаләтләрне, шулай ук район Уставы, район Советы карарлары белән район башлыгы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

16 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3.1. Район Башлыгы урынбасары:

1) район башлыгы булмаган очракта, район Советы эшен оештыруны тәэмин итә;

2) район Советы депутатларына үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтә һәм аларны үз компетенциясе кысаларында кирәкле мәгълүмат белән тәэмин итә;

3) район Советы депутатларының уку, квалификациясен күтәрү мәсьәләләрен координацияли;

4) район советы утырышларын әзерләү һәм үткәрү, район Советы һәм даими комиссияләр утырышлары материалларын бастырып чыгару, депутат запрослары, район Советы депутатлары утырышларында әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне үткәрү һәм тормышка ашыру белән гомуми җитәкчелек итә;

5) район Советының даими һәм вакытлы комиссияләре эшчәнлеген координацияли;

6) совет эшендә хәбәрдарлыкны тәэмин итү һәм җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу буенча җитәкчелек итә;

7) район Советының район составына керүче авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары белән оештыру эшчәнлеге мәсьәләләрендә тиешле үзара бәйләнешен тәэмин итә;

8) гражданнарны кабул итүне гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек итү комиссиясе рәисенә йөкләнә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә
муниципаль районы башлыгы — В.М.Козлов